**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.08.2015 г.Казань № 01-02/584

**"Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтелүенең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен әзерләү һәм административ регламентларын раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен әзерләү һәм административ регламентларын раслау тәртибе турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 17 апрелендәге карары чыгу уңаеннан БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан юридик затлар исемнәрендә "Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә ясалган сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтенең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 (2013 елның 22 октябрендәге 01-02/130, 2014 елның 19 августындагы 01-02/312, 2014 елның 21 ноябрендәге 01-02/495 боерыклар буенча кертелгән үзгәрешләр белән) боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1нче бүлектә:

1.3.2 пунктында «293-07-81» цифрларын «223-07-81» цифрлары белән алыштырырга;

1.3.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән алыштырырга:

«Мәгълүмати стендлар әлеге Регламентның 1.3.1, 1.4, 2.1, 2.3-2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында күрсәтелгән дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат бирә;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«күпфункцияле үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе (алга таба – ераклаштырылган эш урыны);

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәткәндә документларга дөрес булмаган белешмә кертүче, документларга кертелгән белешмәләрнең дөреслеккә туры килмәвенә китерүче министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – рөхсәт бирү турында гариза, гариза) дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау турында сүз бара (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункт). Гариза әлеге Регламентның 2.5 пунктында соралган белешмәләрне күрсәтеп, ирекле формада төзелә.»;

2 бүлектә:

таблицаның беренче юлын түбәндәгечә бәян итәргә:

| Дәүләт хезмәте күрсәтү | Стандарт шарты эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| стандартының шарты исеме | | таләпне билгели торган норматив акт |

таблицаның 2.4 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү ихтыяҗын да исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты,<br>Россия Федерациясе законнарын белән билгеләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелүнең туктатылу вакыты | Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгәнчә, документлар теркәлгәннән башлап өч көн эчендә рөхсәт бирелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү юридик затлар исемнәрендә "Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә ясалган сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) куллануның максатка ярашлылыгы турында дәүләт хакимиятенең кызыксынучы органы бәяләмәсен алганчы туктатыла. | Нигезләмәнең 6 п.<br><br><br><br><br><br>Нигезләмәнең 2 п. |

2.5 пунктында:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты шартының исеме” графасына «гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге» дигән сүзләрдә соң “гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе” дип өстәргә;

«Стандарт шарты эчтәлеге» графасына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

«Гариза һәм документлар кәгазьдә килеш тә, электрон формада да, соралган документларның вәкаләтле зат тарафыннан расланган копиясе сыйфатында, шул исәптән, электрон формада да тапшырыла ала.

Гариза бирүчедән ТР Министрлар Кабинетының 179нчы Карарында һәм Нигезләмәдә күрсәтелмәгән документларны һәм белешмәләрне тапшыруын яки гамәлләрне кылуын таләп итү тыела”;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты шартының исеме” графасына «гариза бирүченең аларны тапшырырга хокукы булган документларның тулы исемлеге» дигән сүзләрдән соң «, шулай ук, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе” дип өстәргә»;

2.8 пунктта:

«Стандарт шарты эчтәлеге» графасына «1. Документларда» сүзеннән соң «алдан килешенмәгән» дип өстәргә;

2.9 пунктта:

«Стандарт шарты эчтәлеге» графасында соңгы абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Юридик затның исемендә «Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә ясалган сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) куллануның максатка ярашлылыгы турында тиешле дәүләт органына запрос юллау дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез була ала”;

2.13 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты шартының исеме” графасына «теркәү вакыты» дигән сүзләрдән соң: «, шул исәптән, электрон формада да» дип өстәргә;

2.14 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты шартының исеме” графасын түбәндәгечә бәян итәргә:

«2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бинага, көтеп тору һәм гаризалар кабул итү урынына, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, язмача һәм мультимедиалы мәгълүмат урнаштыруга карата куелган таләпләр»;

2.15 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты шартының исеме” графасына «сыйфаты күрсәткечләре» дигән сүзләрдән соң «, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи зат белән күпме һәм никадәр вакыт аралашуы,

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкнең ераклаштырылган эш урыннарында дәүләт хезмәте күрсәтелү мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып»;

«Стандарт шарты эчтәлеге» графасына:

«электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлегенең булуы» дигән сүзләрдән соң түбәндәге абзацны өстәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша гариза бирү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мөмкинлекне гамәлгә ашырганнан соң)»;

Түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:

«Гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән аралашулары саны:

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган документларны тапшырганда, дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда – ике тапкырдан да артык түгел (консультацияләрне санамаганда);

Гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә – бер тапкырдан да артык түгел (консультацияләрне санамаганда);

Гариза бирүче белән аралашу вакыты – 15 минуттан да артык түгел.

Күпфункцияле үзәк, ераклаштырылган эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны гариза бирүче http://minjust.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр бердәм порталыннан алырга мөмкин.

3 бүлектә:

3 бүлекнең исемендә «күпфункцияле үзәкләрдә» дигәннән соң «, күпфункцияле үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыннарында» дип өстәргә;

3.1.1 пунктының 1 өлешен түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) гариза бирүчене консультацияләү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән, гариза язу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча»;

3.2 пунктта:

Беренче абзацны түбәндәгечә бәян итәргә:

«3.2. Гариза бирүчене консультацияләү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән, гариза язу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча»;

Өченче абзацка «башка мәсьәләләргә кагылышлы сораулар буенча» дигән сүзләрдән соң «һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә» дип өстәргә;

Бишенче абзацка «һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы консультацияләр» дигән сүзләрдән соң «һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә» дип өстәргә;

3.4 пунктта:

«(ул югында – Бүлек мөдире урынбасарына)» дигән сүзләрне «(ул югында – аны алыштыручы затка)» дип үзгәртергә;

3.4.1 пунктта:

«(ул югында – Бүлек мөдире урынбасары)» һәм «(ул югында – Бүлек мөдире урынбасары тарафыннан)» дигән сүзләрне «(ул югында – аны алыштыручы зат)» һәм «(ул югында – аны алыштыручы зат тарафыннан)» дип үзгәртергә;

түбәндәге эчтәлекле яңа 3.6 пункты белән тулыландырырга:

«3.6. Техник хаталарны төзәтү:

Министрның рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында карарын кабат рәсмиләштерү моңарчы тапшырылган карарда техник хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата) булган очракта башкарыла.

Карарны кабат рәсмиләштерү ирекле формада язылган гариза нигезендә башкарыла. Гариза әлеге Регламентның 3.3.1 пунктында күрсәтелгән ысулларның берсе белән тапшырыла (гариза формасы әлеге Регламентның 2нче кушымтасында тәкъдим ителә). Гаризага дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хаталы карарның күчермәсе, шулай ук, юридик зат вәкиленең вәкаләтләрен раслаган документ күчермәсе беркетелә.

3.6.1. Документ әйләнеше бүлеге белгече:

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итеп ала һәм электрон документ әйләнешендә терки;

Гаризаны электрон документ әйләнешендә министр һәм министрның беренче урынбасары карагач, гаризаны (кәгазьдә килеш кертелгән очракта) Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла,

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән, Бүлеккә тапшырылган гариза.

3.6.2. Бүлек белгече:

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында министр карарының техник хаталар төзәтелгән проектын әзерли;

рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында министр карары проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә (ул булмаган очракта, аны алыштыручыга) юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Бүлеккә гариза юлланган вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдиренә килештерү өчен юлланган карар проекты.

3.6.3. Бүлек мөдире яка аны алыштыручы зат карар проектын килештерә һәм килештерү өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Бүлек белгеченнән проектлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелеп, имза кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган проект.

3.6.4. Министрның беренче урынбасары карар проектын килештереп, аны имза кую өчен министрга юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар Бүлек мөдиреннән проект кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары белән килештерелеп, имза кую өчен министрга юлланган проект.

3.6.5. Министр (ул булмаган очракта ул вәкаләтләр биргән зат) рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кабат теркәлгән карарны раслый. Имзаланган карарны Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар проект раслауга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында кабат рәсмиләштерелеп расланган карар.

3.6.6. Бүлек белгече:

Кабат теркәлгән карарга беренче карар теркәлгән тәртип номерын билгели;

Гариза бирүче техник хатаны төзәтү яки дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасында билгеләгән ысулны кулланып, аның белән элемтәгә керә һәм документның әзер булуы турында җиткерә һәм гариза бирүченең теләгеннән чыгып:

гариза бирүче шәхсән үзе алырга теләгән очракта, кабат рәсмиләштерелгән карарны тапшыру көнен һәм сәгатен хәбәр итә.

карарның күчермәсен гариза бирүчегә юллау өчен Документ әйләнеше бүлегенә тапшыра.

Әлеге пункттагы процедуралар кабат рәсмиләштерелгән карар имзаланган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән карар. Карар күчермәсен алу ысулы турында гариза бирүче белән килешү.

3.6.7. Гариза бирүчегә техник хатасы төзәтелгән дәүләт хезмәте нәтиҗәсен тапшыру.

Документ әйләнеше бүлеге белгече гариза бирүченең теләге буенча, министр карарының күчермәсен гариза бирүчегә тапшыра (юллый).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура министр карарны имзалаган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хата төзәтелеп гариза бирүчегә карарның копиясе тапшырылу (юллану)»;

3.6 пунктны 3.7 пункты дип санарга һәм түбәндәгечә бәян итәргә:

«3.7. Күпфункцияле үзәк, ераклаштырылган эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми”.

5.8 пунктта «тиешле органнарга» дигән сүзләрне «прокуратура органнарына» дигән сүзләр белән алыштырырга;

Кушымтада (белешмәдә) «V.Gizatullina@tatar.ru» сүзләрен «Natalya.Kalinina@tatar.ru» дип алыштырырга.

Административ регламентны түбәндәге эчтәлектәге 2нче Кушымта белән тулыландырырга

"Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирү буенча административ регламентына
2нче Кушымта
(киңәш ителгән форма)
Татарстан Республикасы юстиция министры
Л.Ю.Глуховага

________________________________

(оешманың исеме, оешма җитәкчесенең яки

________________________________)

вәкиленең ИФАи

Техник хатаны төзәтү турында гариза

"Татарстан Республикасы", "Татарстан" атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) ______________________________ исемендә куллануга рөхсәт биргәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

____________________________________________________________________

(бирелгән документ)

күрсәтелгән:

___________________________________________________________________________

Дөрес белешмә: _________________________________________________

___________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтеп, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертүегезне сорыйм.

Шушы документларны терким:

1.

2.

Документның әзер булуы турында ____________________________________________________ хәбәр итүегезне сорыйм

(хәбәр итү ысулы)

_________________ ___________________ (__________________________)».

(дата) (имза) (имзаны ачыклап бирү)

Министр Л.Ю.Глухова